**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6911**
**21.10.2024**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге арендалана торган һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны тормышка ашырганда, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан сатып алына торган күчемле һәм күчемсез мөлкәт өчен түләүне өлешләп түләү срогын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт яки муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге арендалана торган һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны тормышка ашырганда, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан сатып алына торган күчемле һәм күчемсез мөлкәт өчен түләүне өлешләп түләү срогын күчемсез мөлкәт өчен биш ел һәм күчемле мөлкәт өчен өч ел итеп билгеләргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3.Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы  Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев